# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2025 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Чалпы торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**15 ноябрь 2024 ел** **№2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чалпы авыл җирлеге Чалпы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2025 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, өлешчә мобилизацияләүгә чакырылган гражданнар, аларның гаилә әгъзаларыннан һәм хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән һәм махсус хәрби операциягә җибәрелгән гражданнардан, аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Чалпы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Чалпы торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, тоту (Яшьләр урамына, Яңа урамга, Гагарина урамына, Казан урамына, Ленин урамына, Садовая урамына вак таш сатып алу, ташу, салу, эш өчен килешү буенча түләү);
- Урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җайланмалар сатып алу һәм алмаштыру, Чалпы авылы урамнарын яктыртуны ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча хезмәтләре күрсәтү);
- Торак пункт территориясен төзекләндерү (тракторчыга механикалаштырылган кар җыю буенча хезмәтләр өчен түләү, торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларны тоту буенча чит оешмалар хезмәтләре өчен түләү, килешү буенча эшләр өчен түләү ,Чалпы торак пунктында үлән чабу хезмәтләре өчен түләү).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Чалпы авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:// pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Чалпы авыл җирлеге башлыгы __________ А.М.Мөхәмәтшин